**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2016 елның «24» мартыннан** **№ 11-38**

**«Яңа Чишмә муниципаль районында 2015 елда коррупциянең торышы һәм коррупцион шартларны киметү буенча күрелә торган чаралар турында»**

2012 елның 25 апрелендәге ПР-88 номерлы Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы көрәш советы утырышы беркетмәсенең 1.14 пункты нигезендә һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе һәм Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору шартларын кыскарту буенча 2015 елда күрелә торган чаралар турында чыгышын тыңлап, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа Чишмә муниципаль районында 2015 елда коррупциянең торышы һәм коррупцион шартларны киметү буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә, Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе белән берлектә, хокук саклау һәм контроль-күзәтчелек органнарыннан килгән игътибарга алынган актларга (протестлар, тәкъдим итүләр, карарлар) реагирование актларын чыгаручы сәбәпләрне билгеләү предметына анализ үткәрергә тәкъдим итәргә.

3. Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка кичекмәстән Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәттә коррупция шартларын киметү буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**